СОВЕТ
ИРКЕНЯШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИРКӘНӘШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

# КАРАР

23.09.2026

№ 1

Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 июлендәге «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының «Иркәнәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавәми тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышу) оештыру һәм үткәрү тәртибен раслау турында" №1 карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 маддәсенең 8 өлеше, 31 маддәсенең 13 өлеше нигезендә (04.08.2026 елдагы үзгәрешләр белән), Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Иркәнәш авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 июлендәге «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Иркәнәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавәми тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышу) оештыру һәм үткәрү тәртибен раслау турында" №1 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 12 маддәсенең 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Иҗтимагый фикер алышу яисә гавәми тыңлаулар үткәрү вакыты муниципаль берәмлекнең халкына аның үткәреләчәге турында хәбәр иткән көннән башлап, иҗтимагый фикер алышу яисә гавәми тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмәне бастырып чыгарганга кадәр, муниципаль берәмлекнең уставы һәм (яки) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының норматив-хокукый акты белән билгеләнә һәм бер айдан артык була алмый. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча иҗтимагый фикер алышу яисә гавәми тыңлауларның дәвамлылыгы вакыты әлеге проектны бастырып чыгару көненнән башлап, бер айдан күбрәк була алмый.»

2. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе И.З.Камалов